595 номерлы
БОЕРЫК

7.04.2015

Казан шәһ.

Баш мие кан әйләнешенең
көчле бозылулары белән авыручыларга
ашыгыч нейрохирургик ярдәм
оештыру турында

Татарстан Республикасында баш мие кан әйләнешенең көчле бозылулары белән авыручыларга ашыгыч нейрохирургик ярдәм оештыруны камилләштерү максатында б о е р а м:

1. Баш мие кан әйләнешенең көчле бозылулары белән авыручыларга ашыгыч нейрохирургик ярдәм оештыру буенча Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау оешмаларының Эш тәртибен расларга (Кушымта).

2. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы территориаль органнарының, Татарстан Республикасы медицина оешмаларының җитәкчеләренә баш мие кан әйләнешенең көчле бозылулары белән авыручыларга ашыгыч нейрохирургик ярдәмне оештыру буенча Татарстан Республикасы медицина оешмаларының Эш тәртибенә туры китереп баш мие кан әйләнешенең көчле бозылулары (БМКӘКБ) белән авыручыларга ашыгыч нейрохирургик ярдәм оештыруны тәэмин итәргә.

3. 2010 елның 17 октябрендә язылган 279 номерлы «БМКӘКБ белән авыручыларга ашыгыч нейрохирургик ярдәмне оештыру турында» Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының берыгын көчен югалткан дип танырга.

4. Боерык үтәлешенең тикшерүен Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрының беренче урынбасары С.А.Осиповка йөкләргә.

Министр А.Ю. Вафин

2015 елның 7 апрелендә язылган
595 номерлы ТР Сәламәтле саклау
министрлыгы боерыгына
кушымта

Баш мие кан әйләнешенең кочле бозылулары белән авыручыларга
ашыгыч нейрохирургик ярдәм оештыру буенча
Татарстан Республикасы медицина оешмаларының
Эш тәртибе

Бу Тәртип баш мие кан әйләнешенең кочле бозылулары (түбәндә БМКӘКБ) белән авыручыларга ашыгыч нейрохирургик ярдәм оештыруны 15.11.2012 язылган 928н номерлы «Баш мие кан әйләнешенең кочле бозылулары белән авыручыларга ашыгыч нейрохирургик ярдәм күрсәтүнең тәртибен раслау турында» Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының боерыгына туры китереп регламентлаштыра.

Геморрагик инсульт билгеләре КТ-тикшерену яисә МРТ-тикшерену нәтиҗәсе буенча ачыкланган БМКӘКБ белән авыручыларга КТ-тикшерену нәтиҗәләрен алу мизгеленнән 60 минутка соңрак булмаган срокта табиб-нейрохирург консультациясе уздырыла, аның нәтиҗәсе буенча табиблар консилиумы дәвалау тактикасы турында карар кабул итә. Урта мий артериясе бассейнында яман инфаркт белән авыручыларга авыру үсешенең башыннан беренче 24 сәгатьтә табиб-нейрохирург консультациясе уздырыла, аның нәтиҗәләре буенча табиблар консилиумы давалау тактикасы турында карар кабул итә.

Табиб-нейрохирург консультациясе авыручыны карау һәм тикшерү нәтиҗәләрен күзәтеп аңлау юлы белән үтәлә. Югарыда күрсәтелгән срокларда табиб-нейрохирургның кара-каршы үткәрелә торган консультацияне уздырырга мөмкинлек булмаганда ул видеоконференцэлемтә буенча Үзәк медицина сурәтләре архивы системасын куллану белән яисә телефон элемтәсе буенча оештырыла.

Хирургик кулланмаларга күрсәтмәләр һәм аларның күләме табиб-нейрохирург белән «Баш мие эчендәге гипертензив гематомалар белән авыручыларны алып бару буенча рекомендация беркетмәсенә», «Баш мие тамырларының аневризмасы ярылу аркасында кан әйләнешенең субарахноидаль бозылулары белән авыручыларны алып бару буенча рекомендация беркетмәсенә», «Баш мие магистраль артерияләренең стенозланучы зарарлануы белән авыручыларны тикшерү һәм хирургик дәвалау беркәтмәсенә» туры китереп билгеләнәләр.

I. Баш мие эчендәге травматик булмаган гематомалар белән авыручыларга ашыгыч нейрохирургик ярдәм оештыру

1. Баш мие эчендәге травматик булмаган путаменаль һәм таламик локализациянең гематомалары белән авыручыларга ашыгыч нейрохирургик ярдәм оештыру.

1.1. «Регионара клиника-диагностика үзәге» ДАССОның, «2нче номерлы Республика клиник хастаханәсе» ДАССОның, «Арча РҮХ» ДАССОның, «Чистай РҮХ» ДАССОның җирлекләрендә эшләүче кан тамырлары үзәкләрендә баш мие эчендәге травматик булмаган путаменаль һәм таламик локализациянең гематомалары белән авыручыларга консультатив һәм ашыгыч нейрохирургик ярдәм «Регионара клиника-диагностика үзәге» ДАССОның

нейрохирургия бүлегенең табиблары-нейрохирурглары белән күрсәтелә.

1.2. Казан шәһ. «7нче номерлы Шәһәр клиник хастаханәсе» ДАССОның, Казан шәһ. «2нче номерлы Шәһәр клиник хастаханәсе» ДАССОның, Казан шәһ. «12нче номерлы Шәһәр клиник хастаханәсе» ААҖнең, Казан шәһ. «Сугышлар ветераннары өчен госпиталь» ДАССОның, Казан шәһ. «2нче номерлы Ашыгыч медицина ярдәме хастаханәсе» ДАССОның җирлекләрендә эшләүче кан тамырлары үзәкләрендә (неврология бүлекләрендә) баш мие эчендәге травматик булмаган путаменаль һәм таламик локализациянең гематомалары белән авыручыларга консультатив һәм ашыгыч нейрохирургик ярдәм Казан шәһ. «7нче номерлы Шәһәр клиник хастаханәсе» ДАССОның табиблары-нейрохирурглары белән күрсәтелә.

1.3. «ТР ССМ Республика клиник хастаханәсе» ДАССОның, Казан шәһ. «18нче номерлы Шәһәр клиник хастаханәсе» ДАССОның, «Яшел Үзән РҮХ» ДАССОның, «Буа РҮХ» ДАССОның, «Бөгелмә РҮХ» ДАССОның, «Әлмәт РҮХ» ДАССОның, «Татнефть» ААҖ һәм Әлмәт шәһ. МСЧнең җирлекләрендә эшләүче кан тамырлары үзәкләрендә (неврология бүлекләрендә) баш мие эчендәге травматик булмаган путаменаль һәм таламик локализациянең гематомалары белән авыручыларга консультатив һәм ашыгыч нейрохирургик ярдәм «ТР ССМ Республика клиник хастаханәсе» ДАССОның 1нче номерлы нейрохирургия бүлегенең табиблары- нейрохирурглары белән күрсәтелә.

1.4. Яр Чаллы шәһ. «Ашыгыч медицина ярдәме хастаханәсе» ДАССОның, Яр Чаллы шәһ. «5нче номерлы Шәһәр клиник хастаханәсе» ДАССОның, «Алабуга РҮХ» ДАССОның, «Түбән Кама РҮКХ» ДАССОның җирлекләрендә эшләүче кан тамырлары үзәкләрендә баш мие эчендәге травматик булмаган путаменаль һәм таламик локализациянең гематомалары белән авыручыларга консультатив һәм ашыгыч нейрохирургик ярдәм Яр Чаллы шәһ. «Ашыгыч медицина ярдәме хастаханәсе» ДАССОның нейрохирургия бүлегенең табиблары-нейрохирурглары белән күрсәтелә.

2. Баш мие эчендәге травматик булмаган субкортикаль (лобарлы) һәм кечкенә ми локализациясенең гематомалары белән авыручыларга ашыгыч нейрохирургик ярдәм оештыру.

2.1. «Регионара клиника-диагностика үзәге» ДАССОның, «ТР ССМ Республика клиника хастаханәсе» ДАССОның, Яр Чаллы шәһ. «Ашыгыч медицина ярдәме хастаханәсе» ДАССОның, «Бөгелмә РҮХ» ДАССОның, «Татнефть» ААҖ һәм Әлмәт шәһ. МСЧнең, «Буа РҮХ» ДАССОның, Казан шәһ. «12нче номерлы Шәһәр клиник хастаханәсе» ААҖнең, «Түбән Кама РҮХ» ДАССОның җирлекләрендә эшләүче кан тамырлары үзәкләрендә баш мие эчендәге травматик булмаган субкортикаль һәм кечкенә ми локализациясенең гематомалары белән авыручыларга консультатив һәм ашыгыч нейрохирургик ярдәм шушы пунктта барлап чыккан тиешле сәламәтлек саклау оешмаларының табиблары-нейрохирурглары белән күрсәтелә.

2.2. «Әлмәт РҮХ» ДАССОның җирлегендә эшләүче кан тамырлары үзәгендә баш мие эчендәге травматик булмаган субкортикаль һәм кечкенә ми локализациясенең гематомалары белән авыручыларга консультатив һәм ашыгыч нейрохирургик ярдәм «Татнефть» ААҖ һәм Әлмәт шәһ. МСЧнең нейрохирургия бүлегенең табиблары-нейрохирурглары белән күрсәтелә.

2.3. Казан шәһ. «18нче номерлы Шәһәр клиник хастаханәсе» ДАССОның, «Яшел Үзән РҮХ» ДАССОның, «Арча РҮХ» ДАССОның, «Чистай РҮХ» ДАССОның җирлекләрендә эшләүче кан тамырлары үзәкләрендә (неврология бүлекләрендә) баш мие эчендәге травматик булмаган субкортикаль һәм кечкенә ми локализациясенең гематомалары белән авыручыларга консультатив һәм ашыгыч нейрохирургик ярдәм «ТР ССМ Республика клиника хастаханәсе» ДАССОның 1нче номерлы нейрохирургия бүлегенең табиблары-нейрохирурглары белән күрсәтелә.

2.4. Яр Чаллы шәһ. «5нче номерлы Шәһәр клиник хастаханәсе» ДАССОның, «Алабуга РҮХ» ДАССОның җирлекләрендә эшләүче кан тамырлары үзәкләрендә баш мие

эчендәге травматик булмаган субкортикаль һәм кечкенә ми локализациясенең гематомалары белән авыручыларга консультатив һәм ашыгыч нейрохирургик ярдәм Яр Чаллы шәһ. «Ашыгыч медицина ярдәме хастаханәсе» ДАССОның нейрохирургия бүлегенең табиблары-нейрохирурглары белән күрсәтелә.

2.5. Казан шәһ. «2нче номерлы Республика клиник хастаханәсе» ДАССОның, «2нче номерлы Шәһәр клиник хастаханәсе» ДАССОның, Казан шәһ. «Сугышлар ветераннары өчен госпиталь» ДАССОның, Казан шәһ. «2нче номерлы Ашыгыч медицина ярдәме хастаханәсе» ДАССОның җирлекләрендә эшләүче кан тамырлары үзәкләрендә (неврология бүлекләрендә) баш мие эчендәге травматик булмаган субкортикаль һәм кечкенә ми локализациясенең гематомалары белән авыручыларга консультатив һәм ашыгыч нейрохирургик ярдәм Казан шәһ. «7нче номерлы Шәһәр клиник хастаханәсе» ДАССОның нейрохирургия бүлегенең табиблары-нейрохирурглары белән күрсәтелә.

## II. Травматик булмаган субарахноидаль кан саву белән авыручыларга ашыгыч нейрохирургик ярдәм оештыру

Консультатив нейрохирургик ярдәм көчле чорда нейровизуализацияләүдән соң яисә люмбаль пункция ярдәме белән диагностикалаудан соң оештырыла, шуннан соң дәвалау тактикасы билгеләнә.

1. Казан шәһ. «Регионара клиника-диагностика үзәге» ДАССОның, «2нче номерлы Республика клиник хастаханәсе» ДАССОның, Казан шәһ. «2нче номерлы Шәһәр клиник хастаханәсе» ДАССОның, Казан шәһ. «12нче номерлы Шәһәр клиник хастаханәсе» ААҖнең, Казан шәһ. «Сугышлар ветераннары госпитале» ДАССОның, Казан шәһ. «18нче номерлы Шәһәр клиник хастаханәсе» ДАССОның, Казан шәһ. «2нче номерлы Ашыгыч медицина ярдәме хастаханәсе» ДАССОның, «Арча РҮХ» ДАССОның, «Чистай РҮХ» ДАССОның, «Түбән Кама РҮКХ» ДАССОның җирлекләрендә эшләүче кан тамырлары үзәкләрендә (неврология бүлекләрендә) көчле чорда травматик булмаган субарахноидаль кан саву белән авыручыларга консультатив һәм ашыгыч нейрохирургик ярдәм «Регионара клиника-диагностика үзәге» ДАССОның нейрохирургия бүлегенең табиблары-нейрохирурглары белән күрсәтелә.
2. «ТР ССМ Республика клиник хастаханәсе» ДАССОның, «Бөгелмә РҮХ» ДАССОның, «Әлмәт РҮХ» ДАССОның, «Татнефть» ААҖ һәм Әлмәт шәһ. МСЧнең, «Яшел Үзән РҮХ» ДАССОның, «Буа РҮХ» ДАССОның җирлекләрендә эшләүче кан тамырлары үзәкләрендә көчле чорда травматик булмаган субарахноидаль кан саву белән авыручыларга консультатив һәм ашыгыч нейрохирургик ярдәм «ТР ССМ Республика клиник хастаханәсе» ДАССОның 1нче нейрохирургия бүлегенең табиблары-нейрохирурглары белән күрсәтелә.
3. Казан шәһ. «7нче номерлы Шәһәр клиник хастаханәсе» ДАССОның җирлеклегендә эшләүче кан тамырлары үзәгендә көчле чорда травматик булмаган субарахноидаль кан саву белән авыручыларга консультатив һәм ашыгыч нейрохирургик ярдәм Казан шәһ. «7нче номерлы Шәһәр клиник хастаханәсе» ДАССОның нейрохирургия бүлегенең табиблары-нейрохирурглары белән күрсәтелә.
4. Яр Чаллы шәһ. «Ашыгыч медицина ярдәме хастаханәсе» ДАССОның, Яр Чаллы шәһ «5нче номерлы Шәһәр клиник хастаханәсе» ДАССОның, «Алабуга РҮХ» ДАССОның җирлекләрендә эшләүче кан тамырлары үзәкләрендә көчле чорда травматик булмаган субарахноидаль кан саву белән авыручыларга консультатив һәм ашыгыч нейрохирургик ярдәм Яр Чаллы шәһ. «Ашыгыч медицина ярдәме хастаханәсе» ДАССОның нейрохирургия бүлегенең табиблары-нейрохирурглары белән күрсәтелә.

Казан шәһ. «7нче номерлы Шәһәр клиник хастаханәсе» ДАССОның, «ТР ССМ

Республика клиник хастаханәсе» ДАССОның, Яр Чаллы шәһ. «Ашыгыч медицина ярдәме хастаханәсе» ДАССОның нейрохирургия бүлекләренең шартларында баш миенең аневризматик авыруы белән авручыга нейрохирургик ярдәм күрсәтүнең мөмкинлеге булмаган вакытта «Регионара клиника-диагностика үзәге» ДАССОның нейрохирургия бүлеге мөдиренең консультациясе оештырыла.

Салкын чорда ертылган аневризмалар һәм ертылмаган аневризмалар белән авыручылар консультация һәм нейрохирургик дәвалау «Регионара клиника-диагностика үзәге» ДАССОның нейрохирургия бүлеге шартларында алалар.

«Регионара клиника-диагностика үзәге» ДАССОның нейрохирургия бүлеге баш нейрохирургия үзәге булып тора.

## III. Йокы артерияләре прекраниаль өлешләренең кискен стенозлары белән авыручыларга ашыгыч нейрохирургик ярдәм оештыру

Консультатив махсуслаштырылган медицина ярдәме транзитор ишемик атаканың яисә кечкенә инсультның клиник күренеше белән йокы артерияләре прекраниаль өлешләренең кискен стенозлары белән авыручыларга баш миен һәм аның магистраль тамырларын визуализацияләүдән соң оештырыла, аннан соң дәвалау тактикасы билгеләнә.

1. «Регионара клиника-диагностика үзәге» ДАССОның, Казан шәһ. «2нче номерлы Шәһәр клиник хастаханәсе» ДАССОның, Казан шәһ. «12нче номерлы Шәһәр клиник хастаханәсе» ААҖнең, Казан шәһ. «Сугышлар ветераннары госпитале» ДАССОның, «2нче номерлы Республика клиник хастаханәсе» ДАССОның, Казан шәһ. «2нче номерлы Ашыгыч медицина ярдәме хастаханәсе» ДАССОның җирлекләрендә эшләүче кан тамырлары үзәкләрендә (неврология бүлекләрендә) йокы артерияләре прекраниаль өлешләренең кискен стенозлары белән авыручыларга консультатив һәм ашыгыч махсуслаштырылган медицина ярдәме «Регионара клиника-диагностика үзәге» ДАССОның табиблары-нейрохирурглары һәм табиблары-кан тамыры хирурглары белән күрсәтелә.
2. Казан шәһ. «7нче номерлы Шәһәр клиник хастаханәсе» ДАССОның җирлегендә эшләүче кан тамырлары үзәгендә йокы артерияләре прекраниаль өлешләренең кискен стенозлары белән авыручыларга консультатив һәм ашыгыч махсуслаштырылган медицина ярдәме Казан шәһ. «7нче номерлы Шәһәр клиник хастаханәсе» ДАССОның табиблары-нейрохирурглары һәм табиблары-кан тамыры хирурглары белән күрсәтелә.
3. «ТР ССМ Республика клиник хастаханәсе» ДАССОның, Казан шәһ. «18нче номерлы Шәһәр клиник хастаханәсе» ДАССОның, «Бөгелмә РҮХ» ДАССОның, «Яшел Үзән РҮХ» ДАССОның, «Арча РҮХ» ДАССОның, «Буа РҮХ» ДАССОның, «Чистай РҮХ» ДАССОның җирлекләрендә эшләүче кан тамырлары үзәкләрендә (неврология бүлекләрендә) йокы артерияләре прекраниаль өлешләренең кискен стенозлары белән авыручыларга консультатив һәм ашыгыч махсуслаштырылган медицина ярдәме «ТР ССМ Республика клиник хастаханәсе» ДАССОның 1нче нейрохирургия бүлегенең табиблары- нейрохирурглары һәм кан тамыры хирургиясе бүлегенең табиблары-кан тамыры хирурглары белән күрсәтелә.
4. «Әлмәт РҮХ» ДАССОның, «Татнефть» ААҖ һәм Әлмәт шәһ. МСЧнең җирлекләрендә эшләүче кан тамырлары үзәкләрендә йокы артерияләре прекраниаль өлешләренең кискен стенозлары белән авыручыларга консультатив һәм ашыгыч махсуслаштырылган медицина ярдәме «Татнефть» ААҖ һәм Әлмәт шәһ. МСЧнең табиблары-нейрохирурглары һәм табиблары-кан тамыры хирурглары белән күрсәтелә.
5. Яр Чаллы шәһ. «5нче номерлы Шәһәр клиник хастаханәсе» ДАССОның, Яр Чаллы шәһ. «Ашыгыч медицина ярдәме хастаханәсе» ДАССОның, «Түбән Кама РҮКХ» ДАССОның,

«Алабуга РҮХ» ДАССОның җирлекләрендә эшләүче кан тамырлары үзәкләрендә йокы артерияләре прекраниаль өлешләренең кискен стенозлары белән авыручыларга консультатив һәм ашыгыч махсуслаштырылган медицина ярдәме Яр Чаллы шәһ. «Ашыгыч медицина ярдәме хастаханәсе» ДАССОның табиблары-нейрохирурглары һәм табиблары-кан тамыры хирурглары белән күрсәтелә.

Вертебраль һәм йокы артерияләре прекраниаль өлешләренең тромбозы (окклюзиясе) белән авыручылар билгеләнгән тәртиптә, баш миен яңадан васкуляризацияләүгә медицина күрсәткечләрен билгеләү максатында, инсульттан соң 30 көн узгач тикшереп бетерүгә «Регионара клиника-диагностика үзәге» ДАССОның нейрохирургия бүлегенә юнәлтеләләр.

Урта баш мие артериясе бассейнында яман инфаркт белән авыручыларга авыру үсешенең башыннан беренче 24 сәгатьтә табиб-нейрохирург консультациясе оештырыла, аның нәтиҗәләре буенча белгечләр консилиумы белән травматик булмаган баш мие эчендәге субкортикаль (лобарлы) һәм кечкенә ми локализациясенең гематомалары белән авыручыларга ашыгыч нейрохирургик ярдәм күрсәтүче сәламәтлек саклау оешмаларының шартларында дәвалау тактикасы турында карар кабул ителә (Шушы Тәртипнең I разделының 2.1. - 2.5. пунктлары).